ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2024 п.г.т.Алексеевское № 630

**2025 елга Алексеевск муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Рәисенең «2025 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар тарафыннан кертелә торган коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» 2024 елның 14 декабрендәге 962 номерлы Указы нигезендә,

**карар бирәм**:

1. 2025 елга Алексеевск муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифларны расларга:

- социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фонды торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урынны карап тоту, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләме өчен. (1 нче кушымта).

- дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыныннан (наем өчен түләү) файдаланган өчен (2 нче кушымта).

2. Баш мөхәррир Е.Д. Ахманаевага әлеге карарны «Заря» («Таң») район газетасында бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск
муниципаль районы
Башкарма комитетының
28.12.2024 ел № 630
карарына 1 нче кушымта

**Торак урынны карап тоту өчен түләү күләме социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фонды торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләме.**

| № | Хезмәт исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тарифлар (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Алексе-евск штб | авыл җирлек ләре | Алексе-евск штб | авыл җирлек ләре |
| | | | 01.01.2025 тән 30.06.2025 кә кадәр | 01.01.2025 тән 30.06.2025 кә кадәр | 01.07.2025 тән 31.12.2025 кә кадәр | 01.07.2025 тән 31.12.2025 кә кадәр |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 3,71 | 3,71 | 4,53 | 4,34 |
| 2 | Йорт яны территориясен җыештыру һәм ишегалдын карап тоту | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 4,90 | 4,90 | 5,99 | 5,73 |
| 3 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 4,0 | 4,0 | 4,88 | 4,68 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык җайланмалары на техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау: | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | -йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм су түгү санитария-техник челтәрләре | | 2,02 | 2,02 | 2,46 | 2,36 |
| 5 | Торак йортларда йорт эчендәге газ челтәрләренә һәм йорт эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 0,47 | 0,47 | 0,57 | 0,55 |
| 6 | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 1,19 | 1,19 | 1,45 | 1,39 |
| 7 | Вентканалларга һәм төтен чыгаргычларга техник хезмәт күрсәтү | торак урынның гомуми мәйданының аена кв. м | 0,35 | 0,35 | 0,43 | 0,41 |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск
муниципаль районы
Башкарма комитетының
_28.12.2024 ел_ № _630_
карарына 2 нче кушымта

**Дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме**

| Хезмәт исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тарифлар (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Алексе-евск штб | авыл җирлек ләре | Алексе-евск штб | авыл җирлек ләре |
| | | 01.01.2025 тән 30.06.2025 кә кадәр | 01.01.2025 тән 30.06.2025 кә кадәр | 01.07.2025 тән 31.12.2025 кә кадәр | 01.07.2025 тән 31.12.2025 кә кадәр |
| Наем | торак урынның гомуми мәйданының аена 1 кв. м | 7,57 | 7,57 | 9,23 | 8,85 |

**Башкарма комитетының эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**